# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ПЕСӘЙ ТОРАК ПУНКТЫНДА
# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

22.11.2024 ел № 2

2025 елда Татарстан Республикасы Менделеевск
муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең
Песәй торак пунктында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 8 ноябрендәге 9 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылы гражданнар җыены
КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2025 елда үзара салым акчаларын Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Песәй авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын, төзәтү колонияләрендә җәза үтәүче гражданнарны азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

«1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Мичурин, Чишмә, Тукай, Дала урамнары, Дала тыкрыгы урамнары буйлап җирлек эчендәге юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү), Песәй авылындагы юлларны кардан чистарту);

2) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Песәй авылында скважиналар өчен 1 (бер) данә тирәнлек насослары сатып алу);

3) каты коммуналь калдыкларны туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыкларны җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне

бетерү (Песәй авылында санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү буенча хезмәт күрсәтүләр);
4) торак пункт территориясен төзекләндерү (Песәй авылы зиратына коймa урнаштыру, Песәй авылын төзекләндерү элементларын буяу өчен буяулар сатып алу );
5) һәйкәлләрне ( Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихм һәм мәдәният һәйкәлләре булмаган) төзү һәм ремонтлау һәм аларга якын территорияләрне төзекләндерү ( Песәй авылына һәйкәлне күчерү, урнаштыру).»

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Песәй авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Песәй авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы _____________ В.И.Мөхәммәтгалеев